**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 9 октябрендәге 4247 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2014 елның 8 августындагы 4722 номерлы «Казан шәһәренең муниципаль (бюджет, автоном) учреждениесе һәм унитар предприятиесе җитәкчесе вазифасына резерв формалаштыру буенча конкурс уздыру тәртибе турында»гы карарына үзгәреш кертү хакында**

Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 275 статьясы нигезендә Казан шәһәре муниципаль (бюджет, автоном) учреждениесе җитәкчесе вазифасына резерв формалаштыру тәртибен оптимальләштерү максатларында **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2014 елның 8 августындагы 4722 номерлы «Казан шәһәренең муниципаль (бюджет, автоном) учреждениесе һәм унитар предприятиесе җитәкчесе вазифасына резерв формалаштыру буенча конкурс уздыру тәртибе турында»гы карарына (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2014 елның 9 октябрендәге 5809 номерлы, 2014 елның 15 октябрендәге 5943 номерлы, 2014 елның 30 декабрендәге 7655 номерлы, 2015 елның 4 сентябрендәге 3385 номерлы, 2016 елның 5 февралендәге 317 номерлы, 2016 елның 13 сентябрендәге 3796 номерлы, 2017 елның 2 ноябрендәге 4498 номерлы, 2019 елның 29 гыйнварындагы 303 номерлы, 2021 елның 5 маендагы 1115 номерлы, 2022 елның 2 июнендәге 1682 номерлы, 2023 елның 29 маендагы 1487 номерлы, 2023 елның 22 ноябрендәге 3632 номерлы, 2024 елның 1 мартындагы 718 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), 3.3 пунктына «, яисә Казан шәһәренең шул ук эшчәнлек өлкәсендәге муниципаль (бюджет, автоном) учреждениесе җитәкчесе вазифасын биләгән һәм хезмәткәр инициативасы буенча яисә яклар килешүе буенча, эштән азат ителгәннән соң, өч елдан артык вакыт узмау шарты белән, хезмәт килешүе туктатылган затлар белән вакытлы хезмәт килешүе төзү тәртибендә» сүзләрен өстәп, үзгәреш кертергә.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты җитәкчесе Б.Р.Алиевкә йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**